Бәрәңге күзәнәге авырулары

Быел майның беренче көннәрендә һава температурасы бик җылы торып сөендерсә дә, аннан соң килгән суыклар халыкны тәмам аптырашта калдырды. Күпләр әле дә булса бәрәңге утырта алмый интегә. Утыртылган яшелчәләр дә баш төртә алмый азаплана. Татарстан төбәкара ветеринария лабораториясе белгечләре хәбәр итүенчә, халык орлыкка дип калдырылган бәрәңге бүлбеләренең авыруыннан зарлана.

6 БИТ

«Сиделка» дигән һөнәр

Россиядә 8-9 миллион хаста үзләрен караучы хезмәтенә мохтаҗ. Авыруларны караучыларга ихтыяҗ булса да, бу хезмәт һөнәр буларак беркайда да теркәлмәгән икән. Россия Хезмәт министрлыгы авыруларны караучы хезмәтен законлаштырырга тәкъдим итә.

4 БИТ

1990 ЕЛДАН БИРЛЕ ЧЫГА

Шәһри КАЗАН

татмедиа

Сишәмбе | 30.05.2017 | №57 (5819)

www.shahrikazan.com

ТАТАРСТАН БАШКАЛАСЫНЫҢ КӨНДӘЛЕК ИҖТИМАГЫЙ–СӘЯСИ ҺӘМ МӘДӘНИ ГАЗЕТАСЫ

БДИ: БЕРЕНЧЕ СЫНАУ АРТТА КАЛДЫ

Кичә – 29 май көнне, Бердәм дәүләт имтиханнарының төп этабы башланды. Мәктәп укучылары география белән информатика фәненнән имтихан бирде. Аның нәтиҗәсе 14 июньнән дә соңга калмый билгеле булачак.

regnum.ru

Быел 15 меңгә якын бала БДИ сынавы аша уза. Моның өчен республика буенча 83 имтихан бирү пункты әзерләнгән. Рус теленнән имтиханны укучылар иртәгә, ягъни 31 май көнне тапшыра. Ә 2, 9 июнь көннәрендә аларны математикадан профиль һәм төп юнәлешендә сынаулар көтә. Бу көнне барлык 83 пункт та эшләячәк. Кичә исә 15 узәк кенә эшләде. Башка еллардан аермалы буларак, быел имтихан биремнәрен инкассатор машинасында гына алып киләләр. Бу – имтихан материаллары чит кулларга эләкмәсен өчен эшләнә. Кичә дә хакерлар БДИ системасына һөҗүм иткән, ләкин тәртип сакчылары аларның бу эшләрен туктата алган.

Укучылар имтихан тапшыру өчен алдагы еллардагы кебек нигездә җәмгыять белеме, физика, химия, биология фәннәрен сайлаганнар. Әйтик, барлык чыгарылыш сыйныф укучыларының 42,9 проценты җәмгыять белемен сайлаган. Информатика буенча имтиханны чыгарылышларның – 8, ә география буенча нибары 1 проценты гына тапшыра.

– Бүген география буенча – 156, ә информатика буенча 1140 укучы имтихан бирә. Безнең өчен беренче урында – объективлык. Имтихан барышында, аның оештырылуына куелган барлык таләпләр дә нигезләнгән. Безгә укучының үз көче белән имтихан бирүе кирәк. Кызганыч, берничә ел элек кайбер таләпләргә җиңел карадык, –диде Татарстанның мәгариф һәм фән министры урынбасары Илдар Мөхәммәтов.

Искәртик: укучылар математика һәм рус теленнән – мәҗбүри һәм сайлап алып тагын ике фәннән имтихан тапшырырга тиеш. Киләчәктә исә аттестат алу өчен рус теле белән математика гына җитмәячәк. Өч елдан – тарих, биш елдан исә чит тел буенча имтихан да мәҗбүри булачак.

БДИ барган сыйныфта барлык белем бирү плакатлары, китаплар капланган, ә шкафлар һәм тартмалар штамп сугылган кәгазь белән ябыштырып куелган. Кыскасы, укучыларга күчерү мөмкинлегенең «к» хәрефен дә калдырмаганнар.

Сынау биремнәрен эшләү өчен 4 сәгать вакыт бирелсә дә, кайбер укучылар аны 2,5 сәгатьтә тәмамларга өметләнә.

– Безнең балалар өчен БДИ – гадәти имтихан. Аның тирәсендә шау-шу тудырырга кирәкми, укучылар иялләште инде, – диде Илдар Мөхәммәтов.

Сүз уңаеннан, быел имтихан барышын 19 мең кеше күзәтә. Араларында полиция хезмәткәрләре (164), табиблар (170), техник белгечләр (1 087) дә бар. 300гә якын белгеч имтихан бирүче пунктларны электр энергиясе белән өзлексез тәэмин итеп торачак. 17 мең күзәтүче имтихан барышын «СмотриЕГЭ» сайты аша күзәтә. Укучының күчерүен яки башка хокук бозу очрагын күрсәләр, алар махсус номерга смс-хәбәр җибәрә. Имтихан барган аудиториядәге күзәтүчеләр бу хәбәрнең дөреслеген тикшерергә тиеш.

Чыгарылыш имтиханнарының соңгысы 1 июльдә булачак.

Университетларга игътибар зур

Казанда ике көнлек эш сәфәре белән Россия премьер-министры Дмитрий Медведев булып китте. Беренче көнне ул Икътисадны модернизацияләү буенча совет президиумы утырышында катнашты. Чара кысаларында Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов белән алар мәгариф, медицина, ишегалларын төзекләндерүгә юнәлтелгән программалар хакында сөйләштеләр.

tatarstan.ru

Билгеле булганча, республикада 30га якын дәүләт программасы эшләп килә. Быел мәктәпләрне төзекләндерү программасы тәгәлләнде. Ике ел эчендә барлык сырхауханәләрне рәткә китерү бурычы куелган. Рөстәм Миңнеханов лицей һәм ресурс үзәкләрен үстерүгә дә зур игътибар бирелүен искәртте.

Россия премьер-министры Дмитрий Медведев әйтүенчә, соңгы ун елда университетлар системасы үсешенә 114 миллиард сум акча тотылган. Бүген «Югары уку йортлары – инновация булдыру үзәкләре» махсус проекты тормышка ашырыла.

– Ул проект Россия университетларының көндәшлеккә сәләтлелеген ныгытуга, төбәкләрнең инновацион, технологик һәм социаль үсеше өчен университет үзәкләре булдыруга юнәлдерелгән, – ди Дмитрий Медведев.

Утырыштан соң премьер-министр Казан федераль университетының яшь галимнәре белән очрашты. Бу егет-кызлар фән өлкәсендә югары технологияләр кулланып эшлиләр.

– Сезнең университет данлыклы. Бөтен югары уку йортларын дөньякүләм дәрәҗәдәге бер зур, классик университетка туплау дөрес карар булган, – диде Дмитрий Медведев.

Ул яшь галимнәргә фәнни эш белән шөгыльләнү өчен бүлмәләр арендалау процессын җиңелләштерергә кушты.

Сәфәрнең икенче көнендә Дмитрий Медведев тагын бер мөһим вакыйга – Бәйсез Дәүләтләр Бердәмлеге хөкүмәте башлыклары һәм Евразия хөкүмәтара советы утырышларында катнашты. Анда Бәйсез Дәүләтләр Бердәмлеге илләре арасында үзара хезмәттәшлекне үстерү буенча фикер алыштылар. Атом энергиясен тыныч максатларда куллану, контрафакт продукцияне җитештерүгә һәм таратуга каршы эшчәнлек, интеллектуаль милек, геодезия һәм картография-не саклау буенча килешүләр хакында да сөйләштеләр.

Утырышта яңгыраган төп мәсьәләләрнең берсе – Евразия икътисади берлегенә кергән илләр өчен сәнәгать, энергетика, агросәнәгать комплексы өлкәләрендә киртә һәм чикләүләрне бетерүгә кагылды.

– Бизнеска комачауламас өчен, безнең оешмаларга коллегалары белән уңышлы көндәшлек алып барырга ярдәм итү максатыннан, административ тәртип төзергә кирәк. Шуңа да тышкы сәүдә килешүләре белән шөгыльләнә торган, «кәгазьсез» сәүдәгә күчүне күздә тоткан «бердәм тәрәзә» механизмын булдырырга кирәк, – диде премьер-министр.

Киләчәктә бердәмлекнең икътисади нигезләрен ныгытуга кирәклегенә дә басым ясалды.

– Ирекле сәүдә килешүе нигезендә булган каршылыкларны бетерү буенча, электрон сәүдә, дәүләт сатып алулары, техник көйләүләр өлкәсендә үзара бәйләнешне ныгыту өчен, бердәм зур эш алып барырга туры киләчәк. Бәйсез Дәүләтләр Бердәмлеге киңлегендә мөстәкыйль азык-төлек базарын булдыру, транспорт, энергетика өлкәсендә үзара файдалы хезмәттәшлекне үстерү өчен, шартлар тудырачакбыз. Тагын да күбрәк көчне бердәм инновацион эшчәнлек төрләренә ярдәм итүгә юнәлдерәчәкбез, – диде Россия премьер-министры.

КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫК

Хәзер «дворник» та югары белемле

Торактан файдалану идарәләрендә (ЖЭУ) элекке елларда җыен әтрәк-әләм селкенеп йөрер иде. Сантехник, мәсәлән, һәрвакыт салмыш булыр. Мондый нәрсәләргә күптән нокта куелды. Бүген ишегалды җыештыручы да укымышлы.

– Казанда торак-коммуналь хуҗалык тармагында 9467 кеше хезмәт куя. Аларның 58 проценты – югары һәм урта техник белемле, – дип горурлык белән әйтеп утте «эшлекле дүшәмбе» киңәшмәсендә шәһәр Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары – торак-коммуналь хуҗалык комитеты рәисе Искәндәр Гыйниятуллин.

Казанның коммуналь хуҗалык һәм төзелеш колледжы 2013 елдан бирле тармакка төрле белгечләр әзерли. Коммуналь тармакта хезмәт куючыларның һөнәри осталыгын үстерүгә дә нык әһәмият бирелә. Узган ел 3300 эшче квалификация күтәрү курсларында укыган. «Уңайлы торак» идарәче компаниясе каршындагы уку үзәге торак-коммуналь хуҗалык эшчеләренең квалификациясен күтәрүгә махсуслашкан. Соңгы ике елда биредә 1190 кеше осталык дәресләре алган. Азино микрорайонындагы консультация үзәгендә 117 кеше укыган. Идел буе «Практик» уку үзәгендә һәм Хезмәт иминлеге төбәкара ассоциациясендә узган курсларда шәһәрнең торак-коммуналь хуҗалыгының ике мең эшчесе һөнәри белемен күтәргән.

Искәндәр Гыйниятуллин әйткәнчә, күп фатирлы йортларда яшәүчеләрнең дә торак-коммуналь мәсьәләләрдә белемле булуы әһәмиятле.

– «Бердәм Россия» сәяси партиясе башлангычында, «Татарстан Республикасында торак-коммуналь хуҗалык тармагына җәмәгатьчелек контроле төбәк үзәге» коммерциячел булмаган оешмасы белән берлектә, «Белемле кулланучы мәктәбе» һәм «Түләүсез дистанцион уку» проектлары гамәлгә ашырыла. Курсларда 2400 актив граждан укыды инде. Алар торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләүләр билгеләүнең тәртипләрен беләләр, күп фатирлы йорт советлары оештыралар, йортның капиталь ремонтка әзерләүдә һәм капиталь ремонт эшләрен контрольдә тотуда катнашалар, – диде Искәндәр Гыйниятуллин.

Торак-коммуналь хуҗалык тармагындагы эшчеләрнең абруен арттыру максатларында, Казанда быел беренче мәртәбә «Казанның иң оста сантехнигы» конкурсы үткәрелде. Шәһәркүләм бәйгедә Яңа Савин районындагы «Уңайлы торак» идарәче компаниясе эшчесе җиңү яулады. Идел буе районы торак-коммуналь хуҗалыгы идарәче компаниясе – икенче, ә «Совет районы торак идарәсе» идарәче компаниясе өченче булды.

Рәдиф КАРАГАЙ.

«Таттелеком» җәмгыяте мөселманнар өчен махсус тариф әзерли, дип хәбәр итә «Татар-информ». Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин сүзләренә караганда, хәзерге вакытта мобиль тарифның үзенчәлекләре уйланыла.

Мөселманнар өчен махсус

– Мәсәлән, һәр көннең үз хәдисе, аяте турында смс килергә мөмкин. Дини бәйрәмнәр уңаеннан смс-хәбәр килеп ирешсә дә, мөселманнарга артык булмас. «Намазга уят» дигән опция булачак, ягъни намазга торганчы, телефон шалтырап торачак. Тарифта тагын нәрсә булачагын әлегә уйлыйбыз, – дигән мөфти.

«Таттелеком» җәмгыятенең маркетинг буенча директоры Александр Смирнов әйтүенчә, республиканың мөселман җәмәгатьчелеге өчен әзерләнүче тариф июнь аенда гамәлгә кертелергә тиеш.

– Анда дини бәйрәмнәр турында мәгълүмат биреләчәк. Бушлай мобиль интернет күләме дә шактый булачак. Тарифның бәясе «Таттелеком»ның мобиль элемтә буенча базардагы бәяләреннән арзанрак булачак, – дип сөйләгән ул.

Якын арада, сынау режимында, «Ислам ТВ» каналы да эшли башлаячак. «Летай» пакеты булган кешеләрдә ул автомат рәвештә пәйда булачак. Телеканалның кайбер тапшырулары инде әзер. Лобачевский урамындагы бинада студия әзерләнә.

– «Ислам ТВ» каналының билгеле бер аудиториясе булачак. Барлык мөселманнар үзләрендә бу пакетны булдырыр дип уйлыйм. Биредә дини тапшырулар, татарчага тәрҗемә ителгән дини фильмнар карап булачак, – дип белдергән Камил хәзрәт Сәмигуллин.

Кытайга җәяү барган кебек

Президент эшче һөнәрләр чемпионаты нәтиҗәсе белән канәгать түгел

Икътисадчылар да, юристлар да баштан ашкан. Республикага эшче һөнәрләр кирәк! 2014 елдан башланган WorldSkills – эшче һөнәрләр хәрәкәте бу кытлыкны киметә алырмы? Чемпионатка әзерлек тә мактанырлык түгел. Министрлар Кабинетында һөнәри белем бирүче оешмаларның белгечләр әзерләү сыйфатын бәйсез бәяләү уздыру турындагы утырышта Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов әзерлек дәрәҗәсен тәнкыйтьләп чыкты.

15-19 май көнне Красноярск шәһәрендә узган WorldSkills Russia чемпионатында Татарстан команда зачетында икенче урын алды. Без һөнәри осталык буенча бары Мәскәүдән генә калыштык. Чемпионатта барлыгы 109 юнәлеш тәкъдим ителгән иде. Республика командасы 60 һөнәр буенча көч сынашты һәм төрле дәрәҗәдәге 31 медальгә ия булды. Медаль алу – бер, шәхси зачетта һәр катнашучының баллар күрсәткече икенче әйбер икән шул. Икенчесе буенча дөнья дәрәҗәсеннән шактый артта калабыз.

– Без ресурс үзәкләре төзибез, белем бирү оешмаларын төрле яктан тәэмин итәбез. Нәтиҗәсен күрмәгәч, шуның кадәр акча сарыф итүдән ни файда? – дип риторик сорау бирде Рөстәм Миңнеханов. – Бу бит әле Россия чемпионаты гына. Безгә дөнья дәрәҗәсенә күтәрелү Кытайга җәяү барган кебек ерак әле.

Исегезгә төшерәбез, 2014 елдан эшче һөнәрләре әзерләүне дөнья дәрәҗәсенә күтәрү максатыннан, республикада 20 ресурс үзәге ачылды. Моның өчен Татарстан казнасыннан ике миллиард сумнан артык акча тотылды. Ел ахырына кадәр тагын шундый биш үзәк ачу күздә тотыла.

Үз ведомствосы эшчәнлеге буенча беренче тәнкыйть сүзләрен Президент мәгълүматлаштыру һәм элемтә министры урынбасары Дмитрий Вандюковка юдырды.

– Сезнең Казан мәгълүмати технологияләр һәм элемтә техникумы базасында урнашкан ресурс үзәге иң зур кертемлесе булды, минемчә. Без аны булдыру өчен 105 миллион сум акча сарыф иттек. Ә нәтиҗәсе? Акланмагыз! Сезнең төп проблемагыз – сүзегез күп, эшегез аз булуда. Ресурс үзәкләре дә, әзерләнгән белгечләр дә, бу эшкә оешмалар кушылмаса, берни тормый, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Татарстанның мәгариф һәм фән министры Энгель Фәттахов сүзләренчә, эшче һөнәрләрен әзерләүгә кушылмаучы предприятиеләр дә шактый икән. Гәрчә соңыннан бу эшчеләр аларга килсә дә. Ләкин күп компетенцияләр бүген аерым бер министрлыкка карый. Мисал өчен, шул ук Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгына тугыз компетенция беркетелгән. Өчесе буенча республика призлы урыннар алды. Шулар арасында бер алтын һәм бер «Осталык өчен» медале дә бар. Республиканың Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы карамагында булган 21 компетенциядә өч алтын медаль, биш призлы урын һәм бер «Осталык өчен» медале яуланган. Сәламәтлек саклау министрлыгы җитәкчелегендә эшләгән өч компетенциянең икесе республикага алтын медаль алып килгән.

Бурычыңны түләмәсәң, милексез каласың

Россиядә зиннәтле торак хуҗалары һәм алимент түләмәүчеләр тиздән бик авыр хәлдә калырга мөмкин.

«Бурычы булганнарның бердәнбер торагын тартып алу турындагы яңа закон проекты якынча җиде мең алимент түләүчегә кагылачак», – дип әйткән Россия юстиция министры урынбасары Михаил Гальперин.

«Татар-информ» агентлыгы хәбәренә караганда, канун проекты Конституция суды карары нигезендә әзерләнгән. Проект җәмәгатьчелектә төрле фикерләр уяткан. Шул уңайдан кайбер төзәтмәләр дә кертелгән.

«Канун зиннәтле торак хуҗаларына гына кагылмый. Монда бурычларын кайтарырга теләмәгән намуссыз кешеләр дә күздә тотыла. Биредә сүз зур фатирга ия булып, бурычын түләргә акча табарлык кешеләр хакында бара. Алар, оятсыз һәм намуссыз рәвештә, бурычларын кайтармый», – дип яза ТАСС, Гальперин сүзләренә сылтама ясап.

Россия юстиция министры урынбасары әйтүенчә, приставларда алимент түләүчеләргә кагылышлы 880 мең эш бар. Аларның гомуми әҗәт-бурычлары күләме 135 миллиард сумны тәшкил итә.

МӘШГУЛЬЛЕК

Эш урыннарын прокуратура эзли башлаячак

Казанда быелның 1 маена 4583 кеше рәсми рәвештә эшсез сыйфатында теркәлгән.

Дамир БӘДРИЕВ

– Башкалада 15 мең вакансия бар. Бер эшсезгә өч вакансия туры килә. Быелның дүрт аенда 3367 кеше эшкә урнаштырылды, – диде «эшлекле дүшәмбе» киңәшмәсендә Казанның мәшгульлек үзәге директоры Марат Хәйруллин.

Россия Федерациясе Хезмәт министрлыгы мәгълүматларына караганда, илдә эшсезләр күрсәткече хезмәт яшендәгеләрнең 1,2 процентын тәшкил итә. Казанда исә ул – 0,76 процент (узган ел әлеге күрсәткеч 0,91 процент булган).

Казанда өч банкның банкротлыкка чыгуы хәлне беркадәр кискенләштерәчәк. Киләсе өч айда банкларның 2 мең хезмәткәре кыскартылачак.

– Эшсез калган очракларда төшенкелеккә бирелмичә, икенче көнне үк мәшгульлек үзәкләренә мөрәҗәгать итү зарур, – дип киңәш итте Марат Хәйруллин.

Ел башыннан 29 вакансия ярминкәсе оештырылган, шуларда 542 кеше хезмәт урыны табып, эшкә урнашкан. Казандагы предприятиеләрнең 1377 эшче-хезмәткәре өстәмә һөнәрләргә укытылачак. Татарстанның Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгы быелга шушы максатларга 15 миллион 954 мең сум акча күчергән.

– Студент-яшьләр төзелеш отрядларында катнашучыларны эшче һөнәрләренә өйрәтү программасы гамәлдә, – диде Марат Хәйруллин. – Быел 191 егет һәм кыз бетончы, арматурчы, штукатур-буяучы, монтажчы, ташчы һөнәрләренә укырга алынды.

Өлкән яшьтәгеләргә дә махсус стратегия бар. Мәшгульлек үзәге быел да пенсионерларны кондитер, аш-су әзерләүче, электрчы, каравылчы, электр белән эретеп ябыштыручы, тегүче, флорист һәм башка һөнәрләргә укыту өчен курслар оештыра. Өлкәннәрдән 132 кеше җиң сызганып укырга керешкән инде. Физик мөмкинлекләре чикле кешеләрне һәм балигъ булмаганнарны эшкә урнаштыру чаралары күрелә. Быел, мәсәлән, 56 инвалид эшкә урнаштырылган.

Казанда 1669 предприятие һәм оешма үзләрендә вакансияләр булуы турында мәшгульлек үзәгенә хәбәр итеп тора. Ләкин бу предприятие, оешмаларның 2 проценты гына. Калганнары, ягъни 98 проценты эш урыннарын яшерә.

– Мәшгульлек үзәгенә вакансияләр турында мәгълүмат бирмәүче предприятиеләр һәм оешмалар «Россия Федерациясе халкының мәшгульлеге турында»гы федераль законны боза. Шул сәбәпле халык хезмәт базарындагы хәлләр турында тулы мәгълүмат ала алмый, – дип, Марат Хәйруллин прокуратураның әлеге мәсьәләгә игътибар юнәлтүен сорады.

Фикерләре белән уртаклашканда, мэр Илсур Метшин Казанда 2014-2015 елларда хезмәт базарында хәлнең шактый кискен булганлыгын искә төшерде.

– Бүген икътисад тотрыклылана бара. Балигъ булмаганнарны вакытлы эшкә урнаштыру – катлаулы мәсьәлә, әлбәттә, – диде Илсур Метшин. – Совет чорында бу эш билгеле бер тәртипкә салынган иде. Яшьләр слесарь, фрезерчы өйрәнчекләре иде. Хәзер предприятиеләр – акционерлык җәмгыятьләре, аларга таләп куеп булмый. Казанда 70 мең предприятие һәм оешма исәпләнә.

– Предприятиеләр вакытлы эшкә балигъ булмаган бер баланы гына алса да, мәсьәлә чишелер иде, – дип, үтенечен җиткерде Марат Хәйруллин.

Автор фотосы

КАЗАНДА 2017 ЕЛГА ХЕЗМӘТ БАЗАРЫ

- ✔ Мәшгульлек үзәкләрендә 15000 вакансия бар
- ✔ Эшсезлек күрсәткече 0,91 проценттан 0,76 процентка кимегән
- ✔ 4583 кеше рәсми рәвештә эшсез сыйфатында теркәлгән
- ✔ Ел башыннан 29 вакансияләр ярминкәсе уткәрелгән
- ✔ Бер кешегә өч буш эш урыны туры килә
- ✔ 1 майга 5726 кеше эш эзләп мөрәҗәгать иткән

«Сиделка» дигән һөнәр

Россиядә 8-9 миллион кеше авырулар караучы (сиделка) хезмәтенә мохтаҗ. Ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге кешеләрне ярдәмчесез күз алдына китерүе дә авыр. Авыруларны караучыларга ихтыяҗ булса да, баксаң, бу хезмәт, һөнәр буларак, беркайда да теркәлмәгән икән. Россия Хезмәт министрлыгы авырулар караучы хезмәтен законлаштырырга тәкъдим итә. Шәфкать туташлары ассоциациясе белән берлектә, министрлык бу хезмәткә карата һөнәри стандартлар да булдырган. Кыскасы, тиздән яңа һөнәр – авырулар караучы белгеч барлыкка киләчәк.

Эльвира МОЗАФФАР

Яңа һөнәр булдыру фикере кинәт кенә тумаган. «Российская газета» язганча, авырулар караучыга куела торган таләпләрне Россиянең төрле төбәкләрендә уртага салып сөйләшеп, тугыз ел дәвамында әзерләгәннәр. Бу документ Проектлар һәм норматив актлар федераль порталында басылып чыккан.

Һөнәри стандартлар нигезендә, авыруны караучының медицина буенча белеме булу мәҗбүри түгел. Тик авырулар караучыдан беренче медицина ярдәме күрсәтә белү сорала. Бу максатларда алты айлык курслар каралган. Моннан тыш, алар ашарга пешерә белергә, игътибарлы, ягымлы булырга да тиеш.

Авырулар караучы һөнәрен рәсмиләштерү ике як өчен дә отышлы булыр дип саный ун елга якын авырулар караучы Сәрия Хәбибуллина. Аңа бүген – 60 яшь. «Мохтаҗларга ярдәм итү – минем миссиядер, күрәсең», – ди үзе.

Сәрия апа Дөбъяз ягыннан. Ул 22 ел транспорт буенча диспетчер булып эшләгән. Балачактагы хыялы – массаж ясау күнекмәләрен үзләштергәннән соң яраткан эшенә керешә. Тик катлаулы операция кичергәннән соң, аңа массаж ясарга рөхсәт итмиләр. Бер танышы Сәрия апаны авыру энисен карарга чакыра. Бу эшкә башта куркып алынса да, әңгәмәдәшем авыруларга ярдәм итүдән канәгатьлек ала башлый.

– Үзеңне кирәкле итеп тою рәхәтлек бирә. Кечкенәдән ятим мин. Миңа ун яшь булганда, әни кинәт үлеп китте. Шул ук көнне әтигә катлаулы операция ясадылар, озак тормый ул да гүр иясе булды. Әбием белән генә тәрбияләндем. Сабыр, түзем булырга шул чактан ук өйрәнгәнмендер, ә авырулар караучы хезмәтендә бу иң мөһим сыйфатлар, – ди Сәрия апа.

Ул карый торган авыруларның күбесе өлкән яшьтәгеләр. Кайсыларының хәтере юк, психикасында тайпылышлар бар, агрессив. Кайберләрен хастаханәдә операциядән соң карарга туры килә.

Авырулар караучы хезмәте җиңел түгел: аларны юындыру, памперсларын алмаштыру, ашату… Барысыннан да бигрәк, күбесе психологик ярдәмгә мохтаҗ.

– Авырулар белән сөйләшергә, һәр әйткән сүзләре белән ризалашырга туры килә. Агрессив авырулар «юк» дигән сүзне бөтенләй аңламыйлар, – ди тәҗрибәле авырулар караучы.

Әле күптән түгел генә булган бер вакыйга исеннән чыкмый Сәрия апаның. Ул психик тайпылышлары булган бер әбине инсульттан соң тәрбияләгән. Әби балалары белән күптән аралашмый икән. Бер-берсенә үпкәләп яшиләр. Сәрия апа исә аларны татулаштыра алган. Әби дә, балалар да бер-берсеннән гафу үтенеп кочаклашканнар, елашканнар. «Күңелдә ачу саклап яшәргә ярамый, әниләре үлеп китсә, гомерлек үкенеч булачак иде бит», – дип сөенә бу гаилә өчен әңгәмәдәшем.

Сәрия апа фикеренчә, авырулар караучы хезмәтен законлаштыру конфликтлы ситуацияләрне хәл иткәндә дә ярдәм итәр иде. Дөрес, үзенең андый хәлдә калганы юк. Интернет сайтлар, танышлары аша эзләп тапкан кешеләр аңа ышана, хәтта паспортымны да сорап тормыйча, фатир ачкычларын биреп калдыралар, ди. Ничек кенә булмасын, авырулар караучыларның өйне талап чыккан, авыруны кыйнаган очраклар да бар.

Авырулар караучының хезмәтенә акча түләү мәсьәләсендә дә аңлашылмаучанлыклар җитәрлек. Коммерция оешмалары арасында аларны үз максатларында файдаланучылар да юк түгел. Сынау чоры дигән булып, кайбер хуҗалар берничә тәүлек бушлай да эшләтергә мөмкин. Эшләгән өчен түләмәүчеләр дә очрый.

Сәрия апа: «Рәхмәт сүзен ишетү, авыруларның елмаюлы карашларын күрү – акчадан да кадерлерәк», – дисә дә, һәркем үз хезмәтенең тиешенчә бәяләнүен тели торгандыр. Авырулар караучының хезмәте сәгатенә уртача 100 сум дип бәяләнә. Тәүлегенә 1200-3000 сум сораучылар да бар.

Әлеге һөнәрне рәсмиләштерүнең тагын бер ягы бар. Бу үзенә күрә – салым түләмәүче кешеләрне барлау. Җыештыручылар, авыруларны караучылар, нянялар әнә шундый төр һөнәрләргә керә. Тиздән рәсми керем алмаган кешеләрне дә ел саен салым түләргә мәҗбүр итәргә уйлыйлар. Әлегә бу мәсьәлә буенча фикер алышулар бара.

– Авыру әби-бабайларның күбесенең балалары, якыннары эштә.Чарасызлыктан кеше елларга мәҗбүрләр. Еллар дәвамында авыруны карап гаилә белән дуслашып, туганлашып бетәбез. Шуңа да ышанычлы, тәҗрибәле сиделка табу бик мөһим, – ди Сәрия Хәбибуллина.

Сүзен-сүзгә

Юлия АБДРЕЕВА, Татарстанның хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры урынбасары:

– Авырулар караучы бик кирәк. Ялгыз яшәүче өлкән кешеләр, авыру балалары булганнар, инсульт кичергәннәр, катлаулы операциядән соң караучысыз калганнар сиделка ярдәменә мохтаҗ. Татарстанның социаль яклау тармагы әлеге өлкәне үстерергә, җаелдерергә талпынып карады, әмма бу күбрәк сәламәтлек саклау өлкәсенә карый дигән нәтиҗәгә килдек. Авыруны карау өчен медицина ярдәме күрсәтә белү мөһим. Безнең структурага караган социаль хезмәткәрләр күпмедер дәрәҗәдә сиделка хезмәтен башкара, ләкин тәүлек буе авыру янында була алмыйлар. Эшен җиренә җиткереп башкаручы тәҗрибәле сиделкалар бу җәмгыятьтә үз урынын табар дип уйлыйм.

Луиза ГОБӘЕВА, Казан шәһәре 7нче клиник хастаханәсе баш табибының урта медицина персоналы белән эшләү буенча урынбасары:

– Элек-электән сиделка хезмәтен хастаханәләрдә кече шәфкать туташлары башкара. Аларга җыештыру эшләре дә йөкләнгән иде. Хәзер, мәсәлән, безнең хастаханәдә моны клиника компаниясе башкара. Ә шәфкать туташлары авыруларны карый. Казан медицина университетында укучы студентлар буш вакытларында волонтерлык белән шөгыльләнә: авыруларны ашата, асларын алыштыра. Моны да үзенә күрә авырулар караучы хезмәтенә тиңләштерергә була. Хастаханәләр авырулар караучыларга мохтаҗ дип әйтә алмыйм. Ә менә ялгыз яшәүчеләргә сиделкаларның кирәк булуы бар. Бу һөнәрне законлаштырганчы, ныклап уйларга кирәк дип саныйм. Ул белгечләр кайда әзерләнәчәк, моның белән кайсы структура шөгыльләнәчәк? Авыруларны караучыларның эшне сыйфатлы башкаруына да игътибар итәргә кирәк. Бу очракта мәсьәләне төрле яклап карау мөһим.

СОРАУ-ҖАВАП

РАДИКТА РАК ТҮГЕЛ

Җырчы Радик Юльякшинда яман шеш тапканнар икән дип ишеттек. Дәвалану өчен акча җыя башлаган, диләр. Бу акчаларны кемгә тапшырырга? Радикның хәле бик авырмы икән?

***Алия Вафина**, Яшел Үзән.*

Радик Юльякшин – шул ук Элвин Грей – хәбәрне ялган дип белдерә. Бу хакта ул инстаграм битендә дә аңлатып язды. Баксаң, Элвин Грей исеменнән алдакчы мошенниклар «Яндекс-Кошелек» аша акча сорап хәбәрләр җибәрә башлаган. Имеш, җырчы онкология белән авырый һәм аны дәвалау өчен акча кирәк.

– Мин сау-сәламәт, Аллага шөкер! Башкаларга да сәламәтлек телим. Берүк, белгесез кешеләргә акчалар күчерә күрмәгез, ә инде алданган кызларга мошенниклар акчаларын кире кайтарсын иде. Мондый мөрәҗәгать нәтиҗәсез, әлбәттә, шулай да намуслы булыгыз, Аллаһы барысын да күрә, мондый әйберләр белән шаярырга ярамый, – ди Радик.

ПЕНСИЯНЕ САНАУ ҖИҢЕЛӘЯ

Мин 80 яшьтән узган апамны карыйм. Тиздән пенсиягә чыгарга җыенам. Апаны караган еллар минем пенсия стажына керәме? Моның өчен кая мөрәҗәгать итәргә?

***Әминә Фатыйхова**, Чаллы.*

Әйе, 80 яшьтән узган өлкән кешене, шулай ук I группа инвалидны, тумыштан I группа инвалид баланы караучыга акчалата түләүләрдән тыш, тәрбияләгән елларны иминият пенсиясе стажына кертү каралган. Моның отышлы ягы – һәр ел өчен 1,8 балл өстәлә. Бу үз чиратында булачак пенсиянең күләменә тәэсир итә.

– Элегрәк бу төр кешеләрне караганлыкны раслаган документларны теркәлү урыны буенча пенсия бүлегенә алып килергә кирәк булса, өстәмә документлар таләп ителсә, хәзер, Россия Хөкүмәте карары белән, бу процесс җиңеләйтелде. I группа инвалидларны, 80 яшькә җиткән өлкәннәрне караган еллар пенсия фондында булачак пенсионерның шәхси исәп счетында чагылачак һәм пенсияне исәпләгәндә стажга кертеләчәк. Моның өчен өстәмә документлар җыярга кирәк булмаячак, – ди Россия Пенсия фондының Татарстан бүлеге җитәкчесе Эдуард Вафин.

Сүз уңаеннан, Татарстанда ярдәмгә мохтаҗ I группа инвалидларны, 80 яшькә җиткән өлкәннәрне караучылар 73 мең кеше дип исәпләнә. Аларга ай саен 1200 сум акчалата компенсация бирелә. Тумыштан инвалид, I группа инвалид балаларны караучылар – 3,8 мең кеше (әтиәниләр исәпләнми). Алар шулай ук ай саен 1200 сум ала. Инвалид балаларын караган әти-әниләргә ай саен 5500 сум түләү каралган.

«Акыл олимпиадасы спортныкыннан аерылмый»

mon.tatarstan.ru

Ял көннәрендә «Беренче канал»да һәрвакыт «Умники и умницы» тапшыруы бара. Сез нечкәтер, ләкин мин кечкенә вакытта «Дисней» мультфильмнары көткән арада гел шуны карадым. Андагы сорауларның авырлыгына, балаларның акылына карап сокланып утыра идем, ә хәзер телевизион олимпиада үзе Казанда.

БЕЛЕШМӘ

«Умники и умницы» – бөтенроссия гуманитар телевизион олимпиадасы. «Беренче канал»да ул 1992 елның 29 ноябреннән бирле бара. 25 ел дәвамында әлеге тапшыру ярдәмендә өч меңнән артык бала Мәскәү дәүләт халыкара мөнәсәбәтләр институты – МГИМОда бушлай уку хокукына ия була.

Алисә САБИРОВА

26 май көнне, «Тарихи хәтер» проекты кысаларында, Татарстанның Мәгариф һәм фән министрлыгы IV республика «Умники и умницы» уенын оештырды. Бирегә рус теле һәм рус әдәбияты, чит тел, җәмгыять белеме, дөнья сәнгате мәдәнияте, икътисад, тарих кебек фәннәрдән район, республика, халыкара олимпиадалар, бәйгеләрдә җиңү яулаган унынчы сыйныф укучылары катнашты. Финал ярышларында 32 акыллыбашның «Зөя белән Болгар тарихы» буенча белемнәрен сынадылар. Татарстан Дәүләт Советы рәисе урынбасары, «Яңарыш» фондының башкаручы директоры Татьяна Ларионова сүзләренчә, бу теманы республика үзе күтәреп чыккан.

– 20 елдан артык барган, олыларга да, кечеләргә дә бер дәрәҗәдә кызыклы булган тапшыруга нишләп әле үз темабызны тәкъдим итмәскә дип уйладык. Менә шундый тарих, мәдәният аша бай мирасыбызны иң беренче чиратта балаларга күрсәтергә тиешбез. Сүз уңаеннан, быел Болгар шәһәре яр буенда балалар өчен лабиринт ясадык. Мәктәп укучылары хәзер тарихны тотып карап өйрәнә ала, – диде Татьяна Ларионова.

Телевизион олимпиаданың алыштыргысыз алып баручысы, авторы Юрий Вяземский уен барышын карарга үзе килгән иде. Катнашучыларга бу аеруча зур җаваплылык өстәде. Аларның белемнәрен профессор, тарих фәннәре кандидаты үзе сыный бит. Чыгарылыш имтиханнарыннан да ким булмады бу уен.

– Мин сездә инде дүртенче тапкыр. Гомумән, Татарстан балаларына бик зур өмет баглыйм. Алдагы елларда да алар сынатмады, актив иде, – ди Юрий Вяземский. – Бүгенге тема минем үземә аеруча да кызыклы, чөнки тарихи роман язам. Анда вакыйгаларның бер өлеше IX гасыр Болгарында бара. Бу уен минем өчен дә дәрес булачак. Акыл олимпиадасы спортныкыннан бер дә аерылмый. Тырышырга, әзерләнергә, җиңәргә кирәк. Әлбәттә, бәхет факторы да бар. Ләкин аның белән генә дә ерак китеп булмый, – ди профессор.

Яшьләр интернет белемена таяна диләр, әмма телевизион олимпиадада җиңеп чыгу өчен ул гына җитми. Әнә Казанның IT-лицей укучысы Әмир Миңнебаев та Лобачевский китапханәсендәге барлык китапларны актарып чыккан.

– Безнең ораторлык осталыгын, рус теле, тарих буенча белемнәрне сынадылар. Сораулар авыр иде. Иң кыены – сөйләм өлеше. Әзерләнү өчен китапларны укытучым бөтен Казан буенча ташыды. Абдулла Алиш үзәгеннән дә, Лобачевский китапханәсеннән дә китаплар алып укыдым. Без бит интернатта яшибез, үзебезгә урамга чыгарга ярамый, – ди агонист, ягъни уенда катнашучы Әмир Миңнебаев.

Беренче агонда (турда) ике көндәш егетне җиңеп, Казанның 4нче гимназия-интернаты укучысы Мәрьям Ибраһимова җиңү яулады. Хәзер ул киләсе сынауларны Мәскәүдә уза инде.

– Уенга дип махсус әзерләнмәдем. Россия тарихын яхшылап үзләштердем. Бирегә җиңү өчен төпле белем базасы булырга тиеш. Мәскәүгә мин тәҗрибә тупларга барам, – ди кыз.

Җиңүче кыз, шатлыгыннан, күз яшьләрен дә тыеп кала алмады.

ИҖАТ

Чәчәкләрнең гомерен озайтучы

Табигатьнең матурлыгын күрә белү генә аз. КФУның дизайн бүлегендә укучы Кукмара кызы Айсылу Сөләйманованың чын чәчәкләрне файдаланып эшләгән декоратив паннолары белән танышып чыккач, ихтыярсыз шундый фикергә киләсең. Кул астында булган материаллардан ясалган мондый эшләнмәләр бер генә нөсхәдә булуы белән кыйммәт. Аларны кабатлау мөмкин булса да, төп-төгәл күчермәсен ясыйм димә.

– Айсылу, мондый паннолар ясау уе кайдан килде?

– Узган җәйдә бакчаны җыештырып йөргәндә булды бу. Чәчәкләрнең гомере кыска булса да, матурлыкның мәңгелек төшенчә икәнен беләм. Шуңа да бакчада җыйган кипкән чәчәкләрне ташларга кулым бармады, панно ясарга уйладым.

– Беренче эштән үк канәгать калдыгызмы?

– Үзем ошады, әмма баштарак башкаларга күрсәтергә кыймадым. Минем кадәр үк бәяләмәсләр дип курыктым. Иң беренче эшне бик озак һәм җентекләп башкардым. Хәзерге вакытта ул безнең өйдә эленеп тора. Эшләгәндә авырлык тоймыйм, чөнки яратып ясыйм. Композицияләрне алдан планлаштырмыйм. Алар эш барышында туа.

– Илһамны каян аласыз?

– Чәчәк кибетеннән. Анда мин үземә ошаган чәчәкләрне генә алам. Арзан шөгыль түгел, бу эш күп чыгымнар сорый. Киерге-панно – кулланма-гамәли сәнгать өлкәсендә яңа сулыш дияр идем. Ул шуның белән җәлеп итә дә. Эш процессы материалларны бер-бер артлы урнаштырудан гыйбарәт: башта киергә тукыма беркетелә, аннары чәчәкләр һәм декоратив материаллар белән бизи башлыйсың.

– Эшең белән кызыксынучылар шактыйдыр.

– Узган елның сентябрь аенда заказга ясый башладым. Заказны күп алмаска тырышам, чөнки бу минем төп эшем түгел. Укыйсы да бар.

Панного әлле ни исәп тотмыйм, әмма алга таба чәчәкләр белән эшләү, күз явын алырлык букетлар ясау теләгем зур. Башкаларга да яңача уйларга киңәш итәр идем. Талантыгыздан шикләнмәгез! Уңышның 99 проценты тырышлыктан тора дисәм, әллә ни ялгыш ачмам. Моның өчен бары тырышырга һәм тагын бер кат тырышырга гына кирәк!

Сөмбел ХӘСӘНОВА,
Россия ислам институты студенты.

КИҢӘШ САНДЫГЫ

Бәрәңге күзәнәге авырулары

Быел майның беренче көннәрендә һава температурасы бик җылы торып сөендерсә дә, аннан соң килгән суыклар халыкны тәмам аптыраште калдырды. Күпләр әле дә булса бәрәңге утырта алмый интегә. Утыртылган бәрәңгеләр, яшелчәләр дә баш төртә алмый азаплана. «Татарстан төбәкара ветеринария лабораториясе» ФДБУ белгечләре хәбәр итүенчә, халык орлыкка дип калдырылган бәрәңге бүлбеләренең авыруыннан зарлана.

– Безгә орлыкка дип калдырылган бәрәңгене тикшерергә алып килүчеләр шактый, әмма күпчелек кеше күзәнәкнең авыруларын белеп тә бетерми, – ди алар.

Бәрәңге күзәнәгендә нинди авырулар очрый һәм бакчачыга, агрономга аларны ничек ачыкларга? Төбәкара лаборатория белгечләре белән бергәләп әнә шуларга җавап эзләдек.

САБАКЛЫ НЕМАТОДА

Белгечләр әйтүенчә, алар орлыкка калдырылган бәрәңгегә гильментологик һәм микологик анализ үткәрә. Гильментологик тикшерү уздырган вакытта еш кына төрле авырулар очрый. Шуларның берсе – сабаклы нематода. Әлеге авыру бәрәңге үстерелә торган бөтен территориядә дә очрый һәм бик зур зыян салырга мөмкин.

Билгеләре. Сакларга куелган бәрәңгедә авыру билгеләре аеруча нык сизелә. Авыру – бүлбедә барлыкка килгән таптан гыйбарәт. Алар коры черекне хәтерләтә. Төсе исә бәрәңге кабыгыннан бераз караңгырак. Базда вакытта таплар шактый зурая, һәм нәтиҗәдә бәрәңге шартлап ярылырга мөмкин. Бәрәңгегә авыру, нигездә, үсеш чорында йога. Әгәр температура 20-24 градус торса, бу – авыру азар өчен менә дигән шарт дигән сүз.

РИЗОКТОНИОЗ

Микологик тикшерү уздырган вакытта лаборатория белгечләре күпчелек очракта ризоктониоз дигән авыруны ачыклый. Ул аеруча салкын, яңгырлы язда күп очрый икән. Авыру эләккән очракта, бәрәңге сабаклары иртә шиңә, бүлбенең сыйфаты начарлана, тышкы кыяфәте дә ямьсезләнә. Ризоктониоз эләксә, уңыш 20-25 процентка кадәр кимергә мөмкин.

Билгеләре. Бүлбедәге кара «гөмбәчекләр» – авыруның иң төп билгесе. Алар тышкы кыяфәте белән туфрак кисәкләренә охшаш, әмма юылмый һәм бик авырлык белән генә ваклана. Мондый формадагы ризоктониоз бүлбегә зыян китерми диярлек, чөнки алар өстә була. Гөмбәчекләр төп зыянны шытым җибәргәндә сала. Җәй көне җылы һәм дымлы һава торышы торган вакытта, зур үсемлекләрдә авыру үзен «ак аяклар» рәвешендә сиздерергә мөмкин. Шунысы да бар: гөмбәчекләр бүлбедә һәм туфракта өч-дүрт ел да яшәргә сәләтле.

Авыру, бәрәңгедән тыш, яшелчәләргә дә (помидор, кабак, чөгендер) зыян салырга мөмкин. Шулай ук ул күп төрле кыргый чүп үләннәрендә дә – билчән, наратбаш, алабута һәм башкаларда очрый, ди төбәкара лаборатория белгечләре.

ГАДӘТИ КУТЫР

Белгечләр әйтүенчә, соңгы елларда безнең якларда гадәти кутыр дигән авыру да еш очрый башлаган. Монысын да яшелчәчелек киң җәелгән барлык территориядә очратырга мөмкин икән. Авыру үсеш алсын өчен уңай һава торышы һәм туфрак шартлары булу да җитә.

Билгеләре. Әлеге авыруны эләктергән бәрәңгенең сыйфатына зур зыян салына – ул тәмсезләнә, крахмал күләме 5-30 процентка кими, тиз чери. Авыру тамырны, бәрәңге сабагының җирдә яткан өлешен зарарлый. Бүлбедә кечкенә җәрәхәтләр барлыкка килә. Вакыт узу белән, алар зурая. Бераздан әлеге җәрәхәтләр кушылып, тоташ кабык барлыкка килә. Комлы һәм известь күп булган туфракта гадәти кутыр авыруы аеруча күп тарала. Ә коры һәм эссе көннәр моңа ярдәм генә итә. Эссе һава бәрәңге чәчәк аткан вакытта аеруча куркыныч.

– Бакчаларында бәрәңге утырткан кешеләргә әйтер сүзебез бар: янмаган тиресне ашлама сыйфатында файдалану гадәти кутыр авыруының үсеш алуына китерергә мөмкин, – ди белгечләр.

АЛТЫН НЕМАТОДА

Белгечләр әйтүенчә, бәрәңге авырулары арасында иң куркынычы – алтын нематода. Бәрәңгедән тыш, ул помидорга да зур зыян сала. Әгәр авыру кишәрлеккә эләксә, бәрәңге бөтенләй булмаячак, чөнки зарарланган үсемлекләр үсә алмый, яфраклар аксыл төскә керә, бөтерелә һәм акрынлап шиңәчәк.

Билгеләре. Нематода авыруын июль уртасында бәрәңге тамырында табарга мөмкин. Алар бик вак, алтын төстәге шарчыклардан гыйбарәт. Күз күне алар карала һәм шул халәттә кышлый. Яз җиткәч, бер шарчыктан үсемлек согы белән тукланучы 100ләп корт чыга. Зарарлану учагы елдан-ел киңәя. Авыру исә туфрак, аяк киеме, яңгыр яуганнан соң аккан сулар, җил, хайваннар һәм кошлар аша тарала.

– Шулай да күп вакыт бакчачылар зарарланган бәрәңге орлыгы сатып алып, үз җирләрен үзләре агулый. Нематода шарчыклары туфракта җиде-ун ел да яшәргә сәләтле. Авыру эләккән очракта, уңыш 30-80 процентка кадәр югалырга мөмкин. Шуңа күрә авыл хуҗалыгы предприятиеләре җитәкчеләре, агрономнар, республика халкы бәрәңге орлыгын сатып алгач, тикшермичә утыртмасыннар иде. Аеруча читтән кертелгән орлык зарарланган булырга мөмкин. Әгәр инде сораулар була калса, төбәкара лаборатория белгечләренә **8 (843) 237-94-20** телефоны аша мөрәҗәгать итәргә мөмкин, – дип ачыклык кертә белгечләр.

Авыруга каршы нинди дә булса химик чаралар куллану файдасыз, ди алар. Ә менә профилактика чараларыннан бакчачылар берничә киңәшне исләреннән чыгармаса, яхшы булыр иде:

Авыруга каршы тора торган бәрәңге сортын сайларга (Алмаз, Пригожий-2, Розара, Латона, Зекура, Санта һ. б.) кирәк. Аларның да тиз һәм уртача өлгерә торган сортларына өстенлек бирсәгез яхшы.

Бәрәңгене әлеге авыру белән зарарланмый торган культуралар – кәбестә, укроп, кишер, редис, борчак, тукранбаш, күпьеллык үләннәр белән чиратлаштырырга кирәк. Авыруга тиз бирешә торган бәрәңге сортларын бер үк участокта дүрт-биш ел үстермәвең хәерле.

Зарарланган үсемлекләрне таптан очракта, аларны кырдан җыеп алып яндырырга кирәк.

Органик ашламалар (черемә, тавык тизәге) куллану яхшы, чөнки алар кортларны үтерә.

Зарарланган кишәрлектә эшләгәннән соң авыруны башка урынга таратмас өчен, аяк киемен һәм авыл хуҗалыгы әсбапларын дезинфекцияләргә кирәк.

Сабан белән сөргән вакытта җир катламын бик яхшылап эшкәртергә кирәк.

Туфракка авыру эләкмәсен өчен, янган тирес, шулай ук оптималь бәйләнешле азот, фосфор, калий һәм магний ашламаларын кертергә кирәк.

Нематода буенча фитосанитар зоналарда карантин игълан итәргә: әлеге территориядән бәрәңгене алып чыгуны тыярга, бары тик сәламәт орлыкны гына утыртырга, зарарланган кишәрлектә һәрдаим фитосанитар тикшерүе үткәрергә кирәк.

«Яңа Гасыр» телеканалы иншалар бәйгесе башлады

«Счастье – в большинстве» иншалар бәйгесе «Яңа Гасыр» телеканалы башлап җибәргән «В объективе ТНВ – большая семья» социаль проекты кысаларында уздырыла.

Бәйгегә татар һәм рус телләрендә күләме бер-өч биттән артмаган эшләр кабул ителә. Иншалар «Яңа Гасыр» каналының «ВКонтакте» социаль челтәрендәге рәсми төркемендә урын алачак. Җиңүчеләрне телевизор караучылар һәм төркемнең катнашучылары интерактив тавыш бирү ярдәмендә ачыклаячаклар.

Искәртеп узыйк: ярты елга исәпләнгән «В объективе ТНВ – большая семья» социаль проекты барышында канал Татарстанда яшәүче күп балалы гаиләләр белән таныштыра.

– Безнең проект – күпкырлы: татарстанлыларның зур гаиләсен генә күрсәтергә теләмибез, без төрле идарә органнары белән күп балалы гаиләләргә ярдәм итү юлларын эзләрбез, катлаулы сораларны чишәрбез дип уйлыйм, – дип билгеләде Илшат Әминов республика матбугат чаралары өчен оештырылган матбугат конференциясендә.

«Счастье – в большинстве» иншалар бәйгесе октябрь аена кадәр дәвам итә. Иң яхшы өч авторга «Яңа Гасыр» телеканалы махсус бүләкләрен тапшырачак. Иншалар бәйгесе көрәшендә катнашучы үз эшен pr_tnv@mail.ru электрон адресына җибәрергә тиеш. Тулырак мәгълүмат tnv.ru сайтында.

Реклама

31 МАЙ – ТӘМӘКЕДӘН БАШ ТАРТУ КӨНЕ

Тәмәкенең кеше сәламәтлегенә зыяны елдан-ел арта. Фаразларга караганда, 2020 елда балигъ булган кешеләрнең өчтән бере тәмәке тартуга бәйле чирләрдән үләчәк. 2030 елда үлемгә китергән сәбәпләр арасында тәмәке беренче урынга чыгачак. Тәмәке тартучылар үзләренә генә түгел, әйләнә-тирәдәгеләргә дә зарар китерә. Тәмәке тартудан үлгән һәр тугызынчы кеше тәмәке төтенен сулаудан да зыян күргән.

АГУ СУЛАУ

Тәмәке тартучыларны, борыннарын кисеп, Себергә сөргәннәр

Европага тәмәке XV гасырда килә. Билгеле диңгез сәяхәтчесе Христофор Колумб 1492 елда Куба җиренә аяк баса. Ул анда утлы торомбаш һәм үлән көлтәсе тотып йөргән ирләр һәм хатыннарны очрата. Аларның яфрак төргәген торомбаш белән чорнап, авызына кабып, төтен суырганнарын күрә. Тәмәке тартучыларга җәза җитди була. Әйтик, 1692 елда Италиянең биш монахын, тәмәке тарткан өчен, тере көенчә, тәрәзәсез бинага биклиләр. Элек Россиядә тәмәке тартучыларны каеш чыбыркы белән яргаланнар, борыннарын кисеп, Себергә сөргәннәр.

Россиядә тәмәкене ачыктан-ачык сату Петр I заманында башлана. XIX гасырда Россиядә 120 тәмәке фабрикасы була һәм тәмәке җитештерү югары үсеш ала. Тәмәке җитештерүдән алынган салым исәбенә дәүләт алган керем ун миллион сумга җитә. Яхшы сортлы тәмәке җитештерү кыйммәткә төшкәч, фабрика хуҗалары бер-бер артлы арзан тәмәке, махорка җитештерүгә күчә. Тәмәке төтенендә бөтен кешегә мәгълүм булган никотин бар. Ул – алкоголь, морфий, әфьюн, кокаин кебек наркотик матдә. Никотин организмда тупланып, аны әкренләп җимерә. Аннан тыш, тәмәке төтене составында агулы сумалалар, анабазин, никотимин һәм башка агулы матдәләр катнашмасы, шул исәптән аз гына өлеше дә кеше геннарының үзгәрүенә китерә ала торган үтергеч агу – диоксин бар. Вьетнам сугышы вакытында Америка гаскәрләре кулланган агулы матдәнең төп өлеше сыйфатында диоксин файдаланылган. Ә тәмәке тартучы шушы матдә белән үзүзен акрынлап агулый.

Никотин йөрәк-кан тамырлары системасына гына тәэсир итеп калмый, ашказаны-эчәк авыруларына да сәбәпче. Ул кан тамырлары тибүен ешайта, кандагы гемоглобинны һәм организмның физик мөмкинлекләрен киметә.

Галимнәр тәмәке төтененнән аерып алган бензопирен матдәсен лабораториядәге җәнлекләрнең тире астына кертеп караган. Аның бәләкәй – 2 миллиграмм микъдары да шеш барлыкка китергән. Тәмәке сумаласы яман шеш авыруларын тизләтә.

Кайбер кешеләр, Коръәндә тәмәке турында бер сүз дә әйтелмәгән, ул зур гөнаһка керми, дип сөйләнергә яраталар. Бу турыда Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.с.)нең бер хәдисе бар: «Көлли исрафүн хәрамүн». Һәр исраф кылу – хәрам, дигән сүз. Тәмәке ул – исраф. Акчаны, гаиләңнең хакын җилгә очыру, яндыру. Икенчедән, Аллаһ безгә сәламәтлекне әманәт итеп биргән. Сәламәтлегегезне саклагыз, дигән. Сәламәтлекне саклау – безнең бурычыбыз. Ә тәмәке тартучы Аллаһның биргән сәламәтлеген исраф кыла, юкка чыгара. Өченчедән, Аллаһ безгә һаваны да әманәт итеп биргән, һәм ана карынында чакта, ягъни 4 ай да 10 көн вакытта фәрештәләр җан индергәндә сулаячак һаваны да безгә тәгаенләп куялар. Аны сулап бетерәсеңме, тәмәке итеп төтенгә очырасыңмы? Һава безгә сулар өчен бирелгән, ә без аны тәмәке төтененә исраф итәбез.

Тарту-тартмау һәркемнең үзенә бәйле. Теләмәгән кешене берәү дә көчләп тарттырмый. Бу начар гадәткә укучы балалар, үсмерләр өйрәнүе аяныч, чөнки буыны да ныгып өлгермәгән үсмернең организмы нечкә, агуга тиз бирешүчән. Америка галиме Гуль исәпләвенчә, тәмәке тарткан үсмерләрнең, тартмаучыларга караганда, хәтер ныклыгы – 5, ятлау сәләте – 4,5, исәпләү сәләте 5,5 процентка ким. Тәмәке тартучы укучыларның 50 проценты начар укый. Һәр сигарет 15 минутлык гомерне кыскарта, ди галимнәр. Көненә биш сигарет тарткан кешенең эшкә сәләтлелеге 40 процентка кимүе билгеле. Тәмәке тартучылар, тартмаучыларга караганда, юл һәлакәтенә ике тапкыр ешрак очрый.

Рузилә ШАКИРОВА,
Казан.

Тартуны ничек ташларга?

БЕРЕНЧЕ КАГЫЙДӘ

Тәмәке тартуның зыянлы булуын тирәнтен аңлау. Бу кагыйдәдә тәмәкенең зыянын күзаллап, конкрет кешеләр мисалында тәмәке тартудан бит тиресенең аксыл-сары төскә керүен, югәлләвен, тын кысылуын күрергә кирәк. Кан тамырларының кысылуы, яман шеш, башка авырулар турында әйтеп тә торасы юк. Шушы әчке инануның башкаларны күзәтү нәтиҗәсендә көчәюе бик мөһим. Кешенең күңелендә курку туа һәм тәмәкене тизрәк ташларга кирәклегенә ышанычны ныгыта.

ИКЕНЧЕ КАГЫЙДӘ

Организмның гаҗәеп сыйфаты – аның табигый сәләте, зарарлы гадәттән арынырга даими омтылуы. Әгәр беренче көч шәхеснең аңыннан, аның рухи ышануыннан килсә, икенче көч тәмәке тартучының аңында бәйсез рәвештә яши. Ул – кешенең ихтыяр көче генә түгел, ә организмның даими зарарлы гадәтләрдән арынырга омтылуы. Бу көчкә таянырга кирәк. Организм сезнең зарарлы гадәтләрегез белән көрәшүенең нәтиҗәләрен кичекмәстән күрсәтер. Төнлә гырылдавыгыз, йөткерүегез үтәр, тын алу яхшырыр, тауга менгәндә тыныгыз кысылмас, йөрәгегез дә бик арымас, буыннарда көч артуын тоярсыз.

ӨЧЕНЧЕ КАГЫЙДӘ

Шатлык һәм иминлек тойгысы. Сез алсу йөзле, һәрвакыт саф, аек фикерле булырсыз, акчагызны тәмәке сатып алуга туздырмассыз, кесәгезгә тәмәке, шырпы, кәгазь тутырып, кемнәндер сорап һәм тәпчек җыеп йөрмәссез. Өстәвенә көн саен тәнегезне салкын су белән ышкысагыз, иң яхшы сыйфатларның барысына да ия булырсыз.

ПОЧТАДАН

Туган көн

Бүген минем туган көн
Кунак килә торган көн
Әни мине күршеләргә
Кертеп куя торган туган көн.

(Клара Булатова)

Әлеге шигырь юлларын миңа танышым күрсәтте. «Безнең дә шуңа охшаш вакыт булган иде, – диде аннан. – Бәлки күпләргә ят булып тоеладыр,тулай торакта яшәүне аңламыйлардыр. Шунда торып алырга туры килде. Ирем белән икебезнең яшь чаклар. Шулай да тормыш корып җибәреп йорт җиткезү дигән максатлар белән яшибез. Бер киңәш-табыш булмасмы дип, улыбызның ике яше тулган көне уңаеннан, дусларны чакырдык. Алар буш түгел: хатыннары – кәнфит, торт, ирләре эчемлек алып килгән. Кич утыра башладык. Сыралы табын янында йөрмәсен дип, кечкенә улымны гомуми кухняга чыгардым, берничә уенчыгын да куйдым. Анда плитәләр, сандык, тартма, банкалар һәм башка кирәк-яраклар. Кунакларны хөрмәтләгән арада тиз генә улымны барлап керәм. Туган көне март аенда. Тәрәзәдән ябалак-ябалак кар яуганны күзәтә ул. Кухня шыксыз, салкын. Башлык, итек, тунын кидереп куйдым. Бүлмәдә табын гөрли. Тормыш иптәшем җәйлап кына каян җир алу, ничек нигез корып җибәрү турында кызыксына. Кухняга тәлинкә, кашык юарга чыкканда, нәни улым чүп чиләге кырына тезләнгән иде. Салкын бармакларын сөрткәләп алдым да өстәлдән берничә кисәк казылык чыгарып тоттырдым. Бүлмәдә җылы, кунаклар шап кәефтә. Җырлашкан арада ялт кына кухняга омтылам. Улым өшегән, асты, чалбар балаклары юешләнеп, битараф кына сандык янына чүмәшкән. Күзләре ярым йомык. Бүлмәгә кереп, чәй тәкъдим иттем. Кунаклар таралышуга, ирем улымны итәгенә алып сөйде, битләреннән үпте. Юындырып, җылы урынга салганда: «Бүтән беркайчан да баланың туган көнен болай уздырмам», – дип сүз бирдем. Иншалла, һәр елны бүлмәне шарлар белән бизәп, балалар чакырып, тәмле ризыклар белән үткәрдек, инде оныклар бәйрәмнәренә сөенеп катнашам», – диде танышым.

«Туган көнем җәй уртасында, – диде икенче танышым. – Ничә яшьтә булуымны төгәл хәтерләмим, күп вакытлар үткән, бәлки биш-алты яшьтәдер. Иртән әни: «Кызым, бүген синең туган көнең, тәбрик итәм. Без әтиең, абыйларың белән утын әзерләргә урманга китәбез, бәпкә-чебешләрне карарсың», – диде. Моңсу булып китте. Йорт тирәсендә чебешләр белән мавыгып, көнне башладым. Бераздан, өйгә сулпән генә кереп, караватт читенә утырдым. Шунда кинәт аякны чеметтеләр. Сискәнеп, аска карадым. Караватт астыннан, елмаеп-көлеп, минем яшьтәге күрше малайлары килеп чыкты. «Туган көнең белән!» – дип, үзләре әзерләгән уенчыкны бирделәр. Җептән бушаган кәтүк, шырпы кабы, түгәрәкләп кискән сабын һәм сузылмалы нечкә җеп кисәкләреннән машина ясаганнар. Шырпыга ураган җепне әкренләп җибәргәч, ул уенчык кузгалып бераз бара. Көне буе шул уенчык белән мәш килдек. Кичке якта ишегалдына хуш исле каен, имән агачлары кайтарып бушаттылар. Без, балалар, бүрәнәләр өстендә сикерештек, яңа киселгән урыннарны сыпырып карадык. Әни куян күчтәнәче бирде, урман чәчәкләреннән җыйнак гөлләмә сузды, чәчләремнән сыйпады. Искиткеч рәхәт булды. Никадәр арыган булса да, әни безне, аерым өстәлгә утыртып, кайнар коймак белән сыйлады. Бу көн якты истәлек булып калды».

Хәзер күпчелек әти-әни бала туар алдыннан ук аның бәйрәмнәрен зурлап үткәрүне алдан планлаштырып куя. Сабыеңны кочагыңа алып: «Синең туган көн – безнең өчен иң кадерле бәйрәм», – дип ярату, дусларын чакыру шатлыклы вакыйга шул.

Лүзия САЛИХОВА,
Казан.

Икеләтә бәхет

Узган атнада Казанда «Икеләтә бәхет» дип аталган игезәкләр очрашу-бәйрәме узды. Чара «Крылья Советов» паркында ел саен уздырыла торган бөтенроссия «Илнең бөтен паркларында – икеләтә бәхет» акциясе кысаларында үтте. Бәйрәмгә килгән игезәкләр өчен парад, мастер-класслар, анимация, фотосессия, фотокүргәзмә, балалар иҗат коллективларының концерт чыгышлары оештырылган иде. Алар матур итеп бизәлгән игезәкләр арбалары конкурсында да катнаштылар. Шунда ук хәйрия ярминкәсе дә узды. Анда җыелган акчалар тумыштан авыру булган игезәкләр Яна белән Настяга тапшырылачак.

Илдар Мөхәммәтҗанов фотолары

Киоск эзләгәндә

Газетада язмам чыккач,
Киоск эзләп киттем.
Шактый озын юл үттем,
Урам башына җиттем.
Карап барам күзләремне
Мөмкин кадәр зур ачып.
Карашымнан һич кенә дә
Калмасын диеп качып.
Шактый ук ерак киттем:
Ул арада алты кафе,
Җиде аптека үттем,
Очрады биш кибет тә,
Чутсыз чәчтарашханәләр,
Берсе гел махсус эткә.
Теш дәвалау кабинеты,
Нишләптер, һәр почмакта.
Туңдырма, кола саталар,
Хәтта бар өчпочмак та.
Дәваханәнең төрлесе –
Кытае һәм Тибеты.
Монысы нәрсә дигән идем –
Бусы чәчәк кибете.
Газет-журнал киоскасын
Әллә инде мур корган.
Кайдан эзлим тагын дисәм,
Беткән инде бу урам.
Икенчесенә борылдым,
Бер кафега орындым.
Киоск кына юк һаман,
Арыдым инде тәмам.
«Язылсаң, эзләп йөрмәссең!» –
Киңәшегез акыллы.
Тик төштән соң бугай диләр
Без татарның акылы.
Хәер, өйгә дә яздырдым
Газет-журнал бер кочак.
Матбугатсыз ничек яшим,
Ул – җан җылытыр учак.
Арканы диванга терәп,
Җайлап укыйм бер көйгә.
Тик, нишләптер, нәкъ шул санын
Китермәгәннәр өйгә.
Бәдрәф кәгазе саталар –
Бик кирәк нәрсә, аңлыйм.
Газет-журнал сата торган
Киоск тик таба алмыйм.
Ачуың да кабарып,
Чыгар шул зәһәрең дә,
Киоск тапмый интек инде
Миллионлы шәһәреңдә...

ЙОЛДЫЗ.

Балачак бәйрәме

Җәйнең беренче көне – 1 июнь – сабый хәтеренә каникуллар белән беррәттән, Халыкара балаларны яклау көненә багышланган матур чаралар белән дә уелып кала. Башкалабыз Казанда бу көнне кызыклы чаралар уздырыла. Яшь буенча гына түгел, ә күңелләре белән сабый булганнар да рәхәтләнеп ял итә алачак.

Гадәттәгечә, Балаларны яклау көнендә Казан Кремле сабыйлар дөньясына әвереләчәк. «Дөнья балачактан башлана» дигән концерт-тамашада 30га якын балалар коллективы чыгыш ясый. «Әдәби ишегалды» кичәсендә китап укып, язучылар белән танышып, эко-фермада төрле хайваннарны сыйпап булачак. Моңа өстәп, Кремль хезмәткәрләре чып-чын балалар рогын да тәкъдим итә. «SaMoStoятельные дети» уенында ЮХИДИ хезмәткәрләре балаларның юл кагыйдәләре буенча белемнәрен сыный.

Гомумән, Казанда чаралар бер көн белән генә чикләнми. 3 июньда Казан «Зообакчасы»на барып татарча концерт тыңлап, җәнлекләр белән танышып кайта аласыз. Шул ук көнне кичкә таба Горький-Әмәт урман-паркы Буяу фестиваленә чакыра.

«КАЗАН КРЕМЛЕ» МУЗЕЙ-ТЫЮЛЫГЫ

«Без Кремльне яратабыз!»
балалар өчен әзерләнгән фестиваль
Вакыты: 11.00-17.00
Керү ирекле

ХИМИКЛАР МӘДӘНИЯТ САРАЕ ПАРКЫ

Ростов курчаклары йөреше
Вакыты: 14.00-16.00
Керү ирекле

«КАЗАН» ГАИЛӘ ҮЗӘГЕ

Йөкле хатыннар һәм яшь аналар фестивале
Вакыты: 17.00-20.00
Керү ирекле

«АК БАРС» ЯШЬЛӘР ҮЗӘГЕ

«Казан каникуллары»
Чаллы дельфинариясе гастрольләре
Вакыты: 11.00-11.50, 15.00-15.50, 19.00-19.50
Билет бәясе: 450 сумнан алып

«РЕСПУБЛИКА» СӘҮДӘ ҮЗӘГЕ

Балаларны яклау көненә багышланган төрле чаралар:
(«Сумо», «Angry Birds» аттракционнары, кабартылган атларда ярыш һ.б.)
Вакыты: 17.00-19.00
Керү ирекле

ҖИҢҮ ПАРКЫ

Пульт белән идарә ителүче уенчык машиналар ярышы
Вакыты: 15.00
Керү ирекле

«КЫРЛАЙ» ПАРКЫ

Сезон ачылышы
Вакыты: 13.00
Керү ирекле

Шәһри Казан

ИНДЕКСЛАР
П2395 (3 тапкыр чыга)
П2430 (пәнҗешәмбе саны)
П2419 (оешмалар өчен)

www.shahrikazan.com

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ (НӘШЕР ИТҮЧЕ) – «ТАТМЕДИА» АҖ
«ТАТМЕДИА» АҖ ФИЛИАЛЫ ҖИТӘКЧЕСЕ –
БАШ МӨХӘРРИР ГӨЛНАРА ИЛЬЯС кызы САБИРОВА.

© Газетада басылган язмаларны файдалану, шулай ук өзекләр китерү өчен, «ШК» редакциясеннән язмача рөхсәт алу мәҗбүри. Редакциянең фикере авторларның фикере белән аваздаш булмаска да мөмкин. Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы булып йөрү мөмкинлеге юк. Кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Реклама һәм игъланнардагы мәгълүматларның дөреслеге өчен аны бирүчеләр үзләре җаваплы.

РЕКЛАМА ХЕЗМӘТЕ
Тел: (843) 562-50-12,

ХАТЛАР БҮЛЕГЕ
Тел: (843) 562-50-03,
E-mail: shahri-kazan@tatmedia.com

НӘШРИЯТ
«Татмедиа» АҖ
420097, Казан, Академия ур., 2

16+

Сатудагы бәясе ирекле

Бу санның тиражы – 1646. Гомуми тираж – 6043.
Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
Заказ 718. Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итү буенча Федераль хезмәттә (Роскомнадзор) 2012 елның 27 августында ПИ №ФС77-50970 нче теркәлү таныклыгы алды. Газета атнага 3 тапкыр – сишәмбе, пәнҗешәмбе һәм җомга көннәрендә чыга. График буенча бу санга 17 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 17 сәгатьтә.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ
420066, Казан,
Чистай ур., 5 нче йорт
Тел.: (843) 562-50-12,
факс: (843) 562-50-07

БАСМАХАНӘ
420066, Казан, Декабристлар ур., 2 нче йорт.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы.
«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы